**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппаратының вазыйфалар буенча составына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты эшчәнлеген оештыру һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 21 июлендәге ПУ-668 номерлы Указы белән расланган (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 15 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән) Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппаратының вазыйфалар буенча составына, аны кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 25 ноябрь
№ ПУ-917

Татарстан Республикасы
Президентының
2021 елның « 25 » ноябрендәге
ПУ- 917 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппаратының вазыйфалар буенча составы**

1. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире, Татарстан Республикасында Террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе.
2. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш киңәшчесе, Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе урынбасары.
3. «Навигатор» яшьләр, инновация һәм профилактика программалары республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе урынбасары, Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссия аппараты җитәкчесе урынбасары.
4. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш киңәшчесе.

___